КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 июнь г.Казань № 691

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турында» 2012 ел, 2 июль, 575 нче карары белән расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турында» 2012 ел, 2 июль, 575 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 октябрь, 909 нчы; 2013 ел, 25 март, 200 нче; 2013 ел, 14 декабрь, 990 нчы; 2014 ел, 25 ноябрь, 912 нче; 2015 ел, 16 июль, 522 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 985 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1084 нче; 2017 ел, 13 апрель, 224 нче; 2017 ел, 8 декабрь, 962 нче; 2018 ел, 16 апрель, 250 нче; 2018 ел, 2 июль, 537 нче; 2018 ел, 20 ноябрь, 1017 нче; 2019 ел, 12 июль, 570 нче; 2019 ел, 25 ноябрь, 1076 нчы; 2020 ел, 23 ноябрь, 1045 нче; 2022 ел, 14 март, 233 нче; 2022 ел, 7 июль, 651 нче; 2022 ел, 9 июль, 662 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 962 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан И.Ш.Галиевны, А.А.Кондратьеваны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасында террорга каршы комиссия аппараты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире Илдус Хәлик улы Гәрәевны (килешү буенча);

Татарстан Республикасының «Движение первых» балалар һәм яшьләр гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлеге советы рәисе урынбасары Ләйсән Ривкат кызы Засыпкинаны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Софья Альфред кызы Мостафинаны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге баш киңәшчесе Александра Анатольевна Шинкаренконы;

Максим Владимирович Трущинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин